СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 262 от 24.10.2018

на № _______ от _______________

# КАРАР

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында

Шәһәр төзелеше эшчәнлегендә гамәлдәге законнарны үтәү максатында Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше Кодексының 32 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 4 өлеше, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясының 5 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 елның 21 ноябрендәге 94 нче карары белән расланган “Саба муниципаль районында җәмәгать тыңлаулары турында Нигезләмә”гә туры китереп, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре муниципаль районның җирле әһәмияттәге сораулары булуын һәм авыл җирлекләре биләмәләрендә муниципаль район җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителүен исәпкә алып, һәм уздырылган җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре йомгаклары буенча, шулай ук Саба районы Прокуратурасының протестын карарганнан соң, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен расларга. (теркәлә).

2. Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында” 2017 елның 13 июнендәге 145 нче карарын көчен бгалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм (http://saby.tatarstan.ru) адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы — Р.Н. Минниханов